| | |
|---|---|
| СОВЕТ СОБОЛЕВСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЮГАРЫ ОСЛАН<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ<br>СОБОЛЕВСКИЙАВЫЛ<br>ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |

РЕШЕНИЕ КАРАР

14.10.2015 с.Соболевское 2-15

«Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Соболевский авыл җирлеге территориясендә физик затлар мөлкәтенә салым турында»Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Соболевский авыл җирлеге Советының 2014 ел 13 нче ноябрь № 269 карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлеге, «Оешмалар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2015 елның 25 сентябрендәге 62-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә

Югары Ослан муниципаль районының
Соболевский авыл җирлеге Советы
карар итте:

1. «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Соболевский авыл җирлеге территориясендә физик затлар мөлкәтенә салым турында» Югары Ослан муниципаль районының Соболевский авыл җирлеге Советы карарына 2014 елның 13 ноябрендәге 269 нчы номерлы карарына үзгәрешләр кертергә:

1.1. Карарның 2 пунктындагы 6 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

6) 2015 елда - 1,2 процент, 2016 елда - 1,5 процент, 2017 елда - 1,8 процент, 2018 елда - 2 процент һәм аннан соңгы елларда Россия Федерациясе Салым кодексының 3782 статьясындагы 7 пункты нигезендә билгеләнә торган исемлеккә кертелгән салым салу объектларына карата; Россия Федерациясе Салым кодексының 3782 статьясындагы 10 пунктының икенче абзацында каралган салым салу объектларына карата.

2. «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Соболевский авыл җирлеге территориясендә физик затлар мөлкәтенә салым турында» Югары Ослан муниципаль районы Соболевский авыл җирлеге Советы карары текстын яңа редакциядә расларга (1 нче кушымта).

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карар 2015 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Совет рәисе,
Югары Ослан муниципаль районы
Соболевский авыл җирлеге башлыгы О.Н.Майорова

Югары Ослан муниципаль районы
Соболевский авыл җирлеге Советының
2015 елның 14 октябрендәге
15 номерлы Карарына
1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Соболевский авыл җирлеге территориясендә физик затлар милкенә салым турында

1. Соболевский авыл җирлеге территориясендә мәҗбүри түләүгә физик затлар мөлкәтенә салым билгеләү һәм гамәлгә кертү.

2. Түбәндәге күләмдә салым ставкаларын билгеләргә:

1) 0,1 процент:

гараж һәм машина - урыннар;

хуҗалык корылмалары яисә корылмалары, аларның һәркайсының мәйданы 50 квадрат метрдан артмый һәм алар шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, дача хуҗалыгы, яшелчәчелек, бакчачылык яисә индивидуаль торак төзелеше өчен бирелгән җир кишәрлекләрендә урнашкан;

2) 0,2 процент:

фатирлар;

бүлмәләр;

3) 0,3 процент:

торак йортлар;

әгәр мондый объектларның проектланучы билгеләнеше торак йорт булса, төзелеп бетмәгән төзелеш объектлары;

составына бер генә торак урыны (торак йорт) булса да керә торган бердәм күчемсез комплекслар;

4) 2 процент:

аларның һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан артып киткән салым салу объектлары;

5) салым салуның башка объектларына карата 0,5 процент;

6) 2015 елда - 1,2 процент, 2016 елда - 1,5 процент, 2017 елда - 1,8 процент, 2018 елда - 2 процент һәм аннан соңгы елларда Россия Федерациясе Салым кодексының 3782 статьясындагы 7 пункты нигезендә билгеләнә торган исемлеккә кертелгән салым салу объектларына карата; Россия Федерациясе Салым кодексының 3782 статьясындагы 10 пунктының икенче абзацында каралган салым салу объектларына карата.

3. Ике фатирдан торган күпфатирлы бер катлы торак йортта фатир милекчеләренә ташламалар билгеләргә, бу фатирның гомуми мәйданындагы утыз квадрат метр салым ставкасының процент өлеше буларак билгеләнә торган суммага исәпләнгән салым суммасын киметү рәвешендә.

Әгәр фатир гомуми өлешле милектә булса, ташламаларның суммасы өлешле милектә катнашучыларның һәркайсы өчен әлеге фатирга милек хокукында пропорциональ рәвештә исәпләнә.

Әгәр фатир уртак милектә булса, ташламалар суммасы уртак милектә катнашучыларның һәркайсы өчен тигез өлешләрдә исәпләнә.

Бу очракта әлеге пункт нигезендә исәпләнгән ташламалар суммасы аны исәпкә алмыйча исәпләнгән салым суммасыннан артып китә алмый.

Совет рәисе,
Югары Ослан муниципаль районы
Соболевский авыл җирлеге башлыгы О.Н.Майорова